ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» октябрь 2025 ел № 159

**Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Комсомол урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан - җирдән файдалану кагыйдәләренең аз катлы торак төзелеше зонасындагы “Кибетләр” (Ж2) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге төзелешләре, 16:09:010124:30 кадастр номерлы, 1 580 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән Сабиров Динар Камил улына шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында ачык тыңлаулар уздыруны билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турында” 2004 елның 29 декабрендәге 191-ФЗ номерлы, “Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законнарга, Арча муниципаль районы Уставы һәм Арча район Советының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 26 маендагы 145 номерлы карарына таянып (2023 елның 31 гыйнварындагы 188 номерлы үзгәрешләр белән), КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Комсомол урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан - җирдән файдалану кагыйдәләренең аз катлы торак төзелеше зонасындагы “Кибетләр” (Ж2) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге төзелешләре, 16:09:010124:30 кадастр номерлы, 1 580 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән Сабиров Динар Камил улына шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында ачык тыңлаулар уздыруны, ситуация планы нигезендә (1 номерлы кушымта), Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт (кече зал) адресы буенча 2025 елның 12 ноябренә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Комсомол урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан - җирдән файдалану кагыйдәләренең аз катлы торак төзелеше зонасындагы “Кибетләр” (Ж2) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге төзелешләре, 16:09:010124:30 кадастр номерлы, 1 580 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән Сабиров Динар Камил улына шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында ачык тыңлаулар уздыру буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (2 номерлы кушымта).

3. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

4. Документлар белән түбәндәге адрес буенча танышырга мөмкин: Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт, эш көннәрендә 8.00дән 12.00гә кадәр, телефон: 3-06-28, 3-21-33 һәм "Интернет" челтәренең Арча муниципаль районы сайтында: http://arsk.tatarstan.ru .

5. Ачык тыңлаулар темасына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 йорт, телефон для справок: 3-21-33, 3-06-28, (шимбә, якшәмбе көннәреннән тыш, көн саен) 2025 елның 10 ноябре 12.00 сәгатькә кадәр.

6. Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 17 йорт; Арча шәһәре, Һ. Такташ ур., 58 йорт; Арча шәһәре, Кленовая ур., 4 йорт; Арча шәһәре, Банк ур., 2А йорты.


7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И. Г. Сираҗиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы башлыгы А.Г.Хисаметдинов

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ
ИНН 1609009523

Арча муниципаль районы башлыгының<br>
2025 елның “ 20 “ октябрь<br>
159 номерлы карарына<br>
1 нче кушымта

Җир кишәрлегенең ситуация планы
Масштаб 1:1000




Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы башлыгы А.Г.Хисаметдинов

Арча муниципаль районы башлыгының
2025 елның “ 20 “ октябрь
159 номерлы карарына
2 нче кушымта

КОМИССИЯ СОСТАВЫ

Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Комсомол урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан - җирдән файдалану кагыйдәләренең аз катлы торак төзелеше зонасындагы “Кибетләр” (Ж2) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге төзелешләре, 16:09:010124:30 кадастр номерлы, 1 580 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән Сабиров Динар Камил улына шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында

| | |
|---|---|
| Мөхәмәдияров Р.Д. | -Арча муниципаль район башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Сәгыйтова Л.Г. | -юридик мәсьәләләр буенча бүлек җитәкчесе; |
| Хәсәнов И.М. | -башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе |
| Абдуллин М.Р. | -Арча районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге җитәкчесе; |
| Касыймов Р.Ф. | -Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы башлыгы А.Г.Хисаметдинов